| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТИМЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТИМӘШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Р Е Ш Е Н И Е КАРАР

2018елның 25 июле
№24

Тимәш авыл җирлеге Советының 17.12.2015 ел, №28 карары белән расланганТатарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тимәш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Тимәш авыл җирлеге Советының 17.12.2015 ел, №28 карары белән расланганТатарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекнең 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә аларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру максатларында калдыклар кабул итүне оештыру тәртибе турында нигезләмә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә калдыкларны кабул итү эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.»;

1.4 пунктта «җыю һәм транспортировкалау» сүзләрен «кабул итүне оештыру буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 бүлектә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыклар кабул итү - Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә аларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, аларны эшкәртүне, утильләштерүне, зарарсызландыруны, урнаштыруны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан урнаштыру максатларында калдыкларны кабул итүне оештыру.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсуслаштырылган оешмалар - ТКО җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар яисә юридик зат.»;

2.3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Калдыкларны транспортировкалауны оештыру - калдыкларны аларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру урыннарыннан күчерү буенча махсуслаштырылган оешмалар эшчәнлеге.»;

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында: Утыз Имәни урамы, 71А йорты - җирле үзидарә бинасы, Киров урамы, 26 йорт - авыл мәдәният йорты бинасы, Нефтепроводчиклар урамы, 20 йорт - Ромашкино РНУ БПОның утырышлар залы, Киров ур., 1А йорты - “Ромашка” балалар бакчасы бинасы, Урман урамы, 20 йорт, Урман урамы, 33 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (pravo.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

«Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе Р.М.Сираев